РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
НОВОЧЕЧКАБСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ЧӘЧКАП
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

08.06.2023 № 1-70

ТР Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, 2003 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, муниципаль норматив актны законнарга туры китерү максатларында, Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлеге Советының 2019 елның 25 февралендәге 62-1 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында» карары белән расланган (12.02.2020 № 79-1, 20.10.2020 № 1-4, 23.11.2020 № 1-6, 22.12.2020 № 1-8, 22.06.2021 № 4-24, 15.07.2021 № 1-25, 06.02.2023 № 2-65 номерлы карарлар редакциясендә) ТР Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (алга таба- Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 19.7 нче пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«19.7. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан тәкъдим ителә торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тәкъдим ителә торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Россия Федерациясенең норматив хокукый актларына ярашлы рәвештә муниципаль хезмәткә кергәндә гражданнар тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматлар, муниципаль хезмәткәрләрнең "коррупциягә каршы тору турында" Федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән бурычларны үтәүләре Татарстан Республикасы Рәисенең норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә башкарыла..»;

1.2. 19.8 нче пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә язарга:

«19.8. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның, шулай ук аларның тормыш иптәшләренең (ирләренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарын контрольдә тотучы Татарстан Республикасы дәүләт органы (дәүләт органы бүлекчәсе яки күрсәтелгән органның коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи зат) Татарстан Республикасы Рәисенең норматив хокукый акты белән билгеләнә».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында

(http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы
Яңа Чәчкап авыл
җирлеге башлыгының
вазифаларын башкаручы И.Х. Шәрәфетдинов